ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№1698 «19» 12 2016 ел

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
территориясендә янгынга каршы
махсус режим кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 02 декабрендәге «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында» 886 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Яңа ел бәйрәм чараларының янгын куркынычсызлыгын, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген саклау, физик һәм юридик затларның мөлкәтен саклау , дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне саклауны тәэмин итү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2016 елның 19 декабреннән 2017 елның 10 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.

2. Мамадыш муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 02 декабрендәге 886 номерлы карары белән билгеләнгән, 1 - 3 классны куркыныч пиротехник эшләнмәләрдән (бенгаль утларыннан, мамык кисәкләреннән тыш) файдалануга карата, түбәндәге территория чикләрендә, тыюны үтәргә тәкъдим итәргә:

сәнәгать, транспорт инфраструктурасы объектлары (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы (шул исәптән линияле) чикләреннән 500 метр;

Торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары чикләреннән, кешеләр күп була торган объектлар, автомобиль юллары чикләреннән 50 метр.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016елның 02 декабрендәге 886 номерлы карары белән расланган исемлеккә кертелмәгән өстәмә

объектларны Мамадыш муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә билгеләргә тәкъдим итәргә.

4. Мамадыш муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «пиротехник әйберләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында» 2009 елның 22 декабрендәге 1052 номерлы карары белән расланган пиротехник әйберләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә;

халык, юридик затлар арасында, шул исәптән пиротехник эшләнмәләр белән ваклап сатуны гамәлгә ашыручы затлар арасында әлеге карар нигезләмәләрен, шулай ук пиротехник әйберләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү өлешендә аңлату эшләре уздыруны оештырырга;

2016 елның 10 декабренә кадәр гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия утырышларында яңа ел бәйрәм чараларын үткәрү урыннарының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләрен карарга;

ирекле һәм муниципаль янгын сагы әгъзаларының янгын сүндерү техникасы белән тәүлек буе кизү торуын оештыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

оператив хезмәтләрне һәм оешмаларны Яңа ел бәйрәм чараларына һәм түбән температуралар чорына әзерләү мәсьәләләре буенча фикер алышырга;

тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу өчен шартлар тудыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашырырга, шул исәптән төзек булмаган су чыганакларын ремонтлауны оештырырга, елның кышкы вакытында су җыю башняларын, туңмый торган тишекләрдән табигый сулыклар белән су алу, су чыганакларына кардан су юлларын чистарту җайланмалары белән җиһазларга;

шәхси автотранспортны турыдан-туры машина кую мөмкинлеге булмау турында халыкка мәгълүмат бирергә.

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының күзәтчелек эшчәнлеген территориаль органнары белән килештереп, пиротехника әйберләрен сату урыннарында куркынычсызлыкны тәэмин итү чараларын күрергә;

пиротехник әйберләрне саклау һәм сату шартларын мониторинглау буенча комиссияләр төзергә;

урам чыршыларын бизәү сыйфатында сертификацияләнгән электр гирляндаларын файдалану;

пиротехник әйберләрне кулланганда куркынычсызлык таләпләрен үтәү чаралары турында халыкка мәгълүмат бирү буенча эш оештырырга;

янгыннар белән вәзгыять катлауланган очракта, тиешле территорияләрдә пиротехник эшләнмәләр куллануны тыю билгеләргә;

2016 елның 19 декабренә кадәр һәр торак пунктта янгын сүндерүнең беренчел чаралары белән җиһазланган пиротехник эшләнмәләр куллану урынын билгеләргә, алардан файдалануны, шул исәптән «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен үтәүне тикшереп торырга һәм бу хакта халыкка хәбәр итәргә;

2-15 гыйнвар көннәрен үткәрүне оештыру максатында Дәүләт янгынга каршы хезмәт хезмәткәрләреннән, янгыннан ирекле саклау әгъзаларыннан, полиция, торак-коммуналь инспекция хезмәткәрләреннән, халыкны социаль яклау бүлеге хезмәткәрләреннән профилактика төркемнәре төзергә.

2017 елда торак йортларда гражданнар белән профилактик әңгәмәләр үткәрергә, шул ук вакытта күп балалы гаиләләрнең, ялгыз картларның һәм имин булмаган гражданнарның яшәү урыннарына аерым игътибар бирергә.

8. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

пиротехник эшләнмәләр җитештерү, саклау һәм сату белән шөгыльләнүче юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга «Пиротехник әйберләрне таратканда һәм файдаланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 22 декабрендәге 1052 номерлы карарын һәм «пиротехник эшләнмәләр куркынычсызлыгы турында» Таможня берлегенең техник регламентын кабул итү турында» 2011 елның 16 августындагы 770 номерлы карарын үтәүне тәэмин итәргә;

автомобильләргә ягулык салу станцияләрен һәм комплексларын эксплуатацияләүче юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга югарыда күрсәтелгән объектларның территорияләрен һәм биналарын бизәгәндә шартлаудан саклануның таләп ителә торган дәрәҗәсе булмаган электр гирляндалары һәм башка иллюминацияләрдән файдалануны булдырмаска;

Татарстан Республикасы территориясендә күпләп һәм ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешмалар җитәкчеләренә законнарда билгеләнгән тиешле сертификатлары (туры килү турында декларацияләре) булмаган пиротехника әйберләрен һәм электр гирляндаларын, шулай ук техник документацияләрендә янгын куркынычы күрсәткечләре һәм янгын куркынычсызлыгы чаралары күрсәтелмәгән Яңа ел бизәнү әйберләрен, ясалма чыршыларны сатуны булдырмау чараларын күрергә.

балансында янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганаклары булган предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә аларны төзек хәлдә тотуга юнәлдерелгән чаралар күрергә, шул исәптән янгын сүндерү автомобильләренең су чыганакларына керүен тәэмин итәргә, шулай ук су чыганакларын кардан һәм боздан вакытында чистартырга;

гражданнарга дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына «112», «01», «02» ашыгыч оператив хезмәтләре телефоннары буенча, шулай ук мөмкин булган башка ысуллар буенча пиротехник әйберләрне санкцияләнмәгән куллану очраклары турында мәгълүмат бирергә.

9. «Татмедиа» филиалы «Нократ («Вятка») ААҖенә Яңа ел бәйрәмнәрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү чаралары турында халыкка мәгълүмат бирүне тәкъдим итәргә.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Э.Фә ттахов